СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ    КАРАР

16.12.2015    4-27

с. Большие Меми

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авылы җирлегенең Уставына таянып, төзекләндерү объектларын карап тотуга, тулаем алганда, Олы Меми авыл җирлегендә төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрүгә карата бердәм таләпләр билгеләү максатыннан,

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен яңа редакциядә расларга. (1 нче кушымта).

2. Олы Меми авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 октябрендәге 19-97 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль район сайтында урнаштырырга, шулай ук Олы Меми авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы    Н.А.Скарлухин